ГЛАВА
МАЙНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МАЙНА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с.Верх.Тат.Майна** **КАРАР**

**30.10.2020** **№ 4**

**«Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Алексеевск муниципаль районының
Майна авыл җирлегенең Горка авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә

**карар бирәм:**

1. 2020 елның 13 ноябренә 09 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлегенең Горка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Майна авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2021 елда үзара салым кертүгә сез, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:
- авыл эчендәге юлларны вак ташлау һәм төзекләндерү;
- җәйге һәм кышкы чорда җирлек эчендәге юлларны карап тоту;
- контейнер мәйданчыгы төзү һәм контейнерлар сатып алу;
- урамнарны яктырту.

ӘЙЕ ЮК».

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Алексеевск муниципаль районының Майна авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

3. Җыен үткәрү урыны итеп түбәндәге адрес буенча урнашкан авыл клубы бинасын билгеләргә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Горка ав., Ленин ур., 2а й.

5. Әлеге карарны Майна авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Горка ав., Ленин ур., 2а й.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Майна авыл җирлеге башлыгы** **Р.Н.Гафиятуллин**